**Сүзләр көче**

**Иләк аша үткәрепләр булса**
**Кеше әйткән барлык сүзләрне,**
**Тормас иде күңел ямаулардан,**
**Сулкылдатмас иде җөйләрне.**

**Сүзләр көче таулар да аера,**
**Адәм балаларын чит итә.**
**Уйламыйча әйтелгән һәрбер сүз,**
**Араларга куя мең киртә.**

**Берләштерә, өмет бирә алар,**
**Дәвалыйлар, өсти ышаныч.**
**Йомшак җилдәй җанны иркәлиләр,**
**Үсендерә, була таяныч.**

**Барыбыз да истә тотса идек -**
**Онытыла әйткән сүзләре,**
**Басылалар йөрәк ярсулары,**
**Тик уелып кала эзләре.**

**Резеда Шәмсуллина**